## Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге башкарма комитеты

## КАРАР

№ 7

« 07 » апрель 2016 ел

Хөкем ителгәннәрнең җәзасын үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен һәм объектларны билгеләү турында

РФ Җинаять кодексы нигезендә 49 статьясының 1 өлеше, 25 статьясының 1 өлеше нигезендә. Урмандеевка авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгәннәр җәзасын үтәгәндә, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә җинаять җәзасы билгеләнгән затларны төзәтү, аларда җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру максатларында Урмандеевка авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар кабул итте:

1.Урмандеевка авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләрне башкару урыннарын билгеләргә :

торак пунктларда: Савгачево авылы,Урмандеево авылы,Сидулово-Ерыклы авылы,Заря Бистәсе,Сосновка Бистәсе,Кече Акташ Бистәсе җинаять – башкару инспекциясе белән килешү буенча.

2. Мәҗбүри эш төрләрен билгеләргә-торак пунктларны һәм зиратларны төзекләндерү һәм яшелләндерү , юл буендагы куакларны кисү , елгалар һәм буалар территориясен чистарту, җинаять-башкару инспекциясе белән килешү буенча карны җыю.

3. Әлеге карарны Аксубай районы буенча ФКУ филиалы белән берлектә Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкару инспекциясе тарафыннан төзәтү яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән һәм Урмандеевка авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд хөкемнәрен үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны Аксубай районы буенча ФКУ филиалы белән берлектә Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча

Идарәсе җинаять-башкару инспекциясе тарафыннан мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән һәм Урмандеевка авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд хөкемнәрен үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.

5. ТР Аксубай муниципаль районы Урмандеевка авыл җирлеге башкарма комитетының 01.03.2016 елгы 6 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылсын.

6. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеевка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында да.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

В. З. Николаев